СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

10.10.2023 г.                  с. Шеланга                  № 30-176

Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең Шеланга авылы торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә, Шеланга торак пунктының бер өлеше халкы төркеменең инициативасын карап чыгып,

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең Шеланга торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 21нче октябренә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Шеланга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 9100 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Шеланга авылының Заводская урамы буенча юлны реконструкцияләү

«ӘЙЕ»                                        «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Шеланга авылы, Завод урамы адресы буенча 7 нче йорт янында 18.00 сәгатьтә уздырырга:

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шеланга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров